**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**КАРАРЫ**

**2024 ел, 23 сентябрь N 251**

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында"04.10.2021 N 70нче карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы:

1."Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында" Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2021 елның дүртенче октябрендәге 70 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

60 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«60.Планнан тыш күчмә тикшерү, 248 - ФЗ Федераль законының 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклардан тыш, прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.

Урынга барып тикшерү уздыру турында контрольдә тотылучы затка, әгәр контроль төре турындагы Федераль законда башкасы каралмаган булса, әлеге Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә урынга барып тикшерү уздыру турындагы карарның күчермәсен җибәрү юлы белән ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.»;

62 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"62. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.".

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы башлыгы –**
**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы Советы рәисе А. Г. Җиһаншин**